# САН СҮЗ ТӨРКЕМЕН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ.

Уен- сәяхәт дәрес.

ИСӘНМЕСЕЗ, ХӘЕРЛЕ КӨН, УКУЧЫЛАР!
ДӨРЕС ҺӘМ УҢАЙЛЫ ИТЕП УТЫРЫГЫЗ.ЯХШЫЛАП ТЫҢЛАРГА ҺӘМ ДӘРЕСТӘ АКТИВ БУЛЫРГА ТЫРЫШЫГЫЗ.
Ә ХӘЗЕР ДӘРЕСЕБЕЗНЕ БАШЛЫЙБЫЗ.

# ВАКЫТ ҺӘМ ЕЛ.

Еллар ике төрле була.Гади ел һәм Кәбисә елы. Гади елда өч йөз алтмыш биш (365)көн. Кәбисә елында өч йөз алтмыш алты (366)көн була.Кәбисә елын белү бик җиңел.Елның соңгы ике саны дүрткә тигез бүленсә, ул кәбисә елы була. Кәбисә елында февраль егерме тугыз (29) көннән тора. 1995 нче ел-гади ел, чөнки 95 дүрткә тигез бүленми. 2000,2008 нче еллар кәбисә еллары иде.

Сүзлек:

Кәбисә елы- високосный год.

1876 567

23 116

1498

67890 84746

3465


978


735 6443

# ТАБЫШМАК:

Уф итәр, пуф итәр,
Төчкеренер дә, почкырыныр,
Ә аннан соң алып китәр
Һәм теләгән җиргә илтәр.


1


Кызыксынучы
Кызыклы грамматика
Белем
Эрудит


Сан төркемчәләре
Тәртип
чама
микъдар
җыю
бүлем

# КЫЗЫКСЫНУЧЫЛАР СТАНЦИЯСЕ











# ТАБЫШМАКЛАР.

1. Бәйләми дә, текми дә,
Каемый да, чикми дә.
Энәләре үзендә,
Җитә, диләр, йөз меңгә.

2. Ике җирдә- ике дүрт,
Икесенә бер сигез.
Күпме булыр барысы,
Тизрәк җавап бирегез.

3. Кешегә җиде тулгач, ул нишли?

4. Нинди сәгать тәүлеккә ике генә мәртәбә вакытны дөрес күрсәтә?

5. Берәү сөйли, берәү тыңлый,
икәве карап тора.

6. Дүртәү йөгерә- берсен-берсе уза алмый.

# САННАРНЫҢ ЯСАЛЫШЫ.

1. Тамыр саннар бер кисәктән (сүздән) тора: ун, егерме, йөз, мең.
2. Кушма саннар кушылып ясала: унбер, уналты, унсигез.
3. Тезмә саннар аерым языла: йөз егерме биш, йөз уналты.
4. Парлы саннар сызыкча аша языла: тугызар-унар, дүртләп-бишләп.



# МӘКАЛЬЛӘР.

1. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
2. Матурлык бер көнлек  дуслык-гомерлек.
3. Бер кешедә бер акыл,  халыкта мең акыл.
4. Ике уйла  бер эшлә.
5. Егет сүзе  бер булыр.
6. Җиде кат үлчә,  бер кат кис.



# БЕЛЕМ СТАНЦИЯСЕ.



# ТЕСТ

| 1 команда | 2 команда |
| --- | --- |
| 1.Саннар язуда ничек белдерелә?<br>а) цифр белән?<br>ә) сүз белән?<br>б) цифр яки сүз белән белдерелә?<br>2.Чама саны<br>а) ничә? Күпме соравына җавап бирә.<br>ә) ничә соравына җавап бирә.<br>б) ничәләп?күпмеләп? соравына җавап бирә. | 1. 0,1,2,3,4,5,6,7,8,9<br>а) гарәп цифрлары?<br>ә) рим цифрлары?<br>2.Бүлем саны.<br>а) ничә? Күпме? Сорауларына җавап бирә.<br>ә) ничәнче?<br>б) ничәшәр? Күпмешәр?<br>в) ничәү?<br>г) ничәләп? Купмеләп? |


1

# ЭЧЕНДӘ САН БУЛГАН СҮЗЛӘР.

Алтын, тун, кунак, йөзек, бертуган, көч, бишек, җидегән, меңьяфрак, йөзем, фикер, көчек.

# ЭРУДИТ СТАНЦИЯСЕ.





# КЫЗЫКЛЫ ГРАММАТИКА СТАНЦИЯСЕ.

Ребусны чишегез:

““




,,



# САН ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ.

Вертикаль юлга микъдар саннарын дөрес итеп урнаштырсагыз, беренче горизонталь юлда башкалабызның исемен укырсыз.



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | т | |
| | | у | у | |
| | | т | к | |
| | | ы | с | у |
| к | а | з | а | н |
| ы | л | | н | |
| р | т | | | |
| ы | ы | | | |
| к | | | | |

